Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы

**КАРАР №24**

Зур Мәшләк авылы — 2024 елның 29 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2023 елның 2 маендагы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»гы 3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Зур Мәшләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2023 елның 2 маендагы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»гы 3 нче номерлы карарына (2024 елның 17 июнендәге 10 нчы номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 1 һәм 2 нче пунктчаларын төшереп калдырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылы, Мәктәп урамы, 13А йорты; Югары Мәшләк авылы, Нариманов урамы, 24а йорты; Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50А йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы — М.М.Шәмсевәлиев